**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү чаралары турында» 2015 елның 15 июлендәге 364 номерлы Указы басылып чыгу белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы һәм 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-328 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы һәм 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү бурычы түбәндәгеләргә йөкләнә:

граждан хезмәтен биләүне дәгъвалаучы гражданга (алга таба – граждан);

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган граждан хезмәте вазыйфаларының тиешле исемлегенә (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) кертелмәгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче һәм Вазыйфалар исемлегенә кертелгән граждан хезмәте вазыйфасын

биләүне дәгъвалаучы (алга таба – Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә.

Керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү бурычы Вазыйфалар исемлегенә кертелгән граждан хезмәте вазыйфасын хисап елының 31 декабренә биләүче Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәре) йөкләнә.»;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган белешмә формасы нигезендә бирелә:

гражданнар тарафыннан – Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә кергәндә;

Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидатлар тарафыннан – Вазыйфалар исемлегенә кертелгән граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә.»;

в) 4 пунктта «Вазыйфалар исемлегендә каралган» сүзләрен «Вазыйфалар исемлегенә кертелгән» сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$. Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә тапшыра.»;

д) 7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

е) 8 пунктта «5 һәм 6 пунктларда каралган» сүзләрен «5, $5^1$ һәм 6 пунктларда каралган» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Граждан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында анықланган белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 3 пункты икенче абзацы нигезендә белешмәләр биргән көннән бер ай дәвамында бирә ала. Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат анықланган белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 3 пункты өченче абзацы нигезендә белешмәләр биргән көннән бер ай дәвамында бирә ала. Граждан хезмәткәре анықланган белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән вакыт беткәннән соң бер ай дәвамында бирә ала.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 8 пункты икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән граждан һәм граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелгән анықланган белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт органы кадрлар хезмәте тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсенә тиешле кадрлар хезмәтенә тапшырылганнан соң биш көн эчендә җибәрелә.»;

з) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Граждан яисә Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында әлеге Нигезләмә буенча бирелгән белешмәләр, шулай ук граждан хезмәткәре тарафыннан ел саен бирелүче керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә. Үзләренең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмә биргән граждан яисә Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелмаган очракта, бу белешмәләр аларның язмача гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарып бирелә.».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы һәм 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәгә, 3 пунктта «башка Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы» сүзләрен «әлеге Вазыйфалар исемлегендә каралган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәвен тикшерү турында» 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 20 августындагы

ПУ-797 номерлы һәм 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәгә, 17 пунктның «д» пунктчасында һәм 20 пунктның «г» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты төзегән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә» сүзләрен «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы Указының 2 пункты «г» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 13 октябрь
№ ПУ-988